**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 18 октябрендәге 4430 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 15 октябрендәге 4320 номерлы «2024 елда Казан шәһәрендә БРИКС илләре саммитын әзерләү һәм уздыру чорында транспорт чаралары хәрәкәтен, тукталышын һәм туктап торуын вакытлыча чикләү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы «Төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә туктатуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә:

1. **Карар бирәм**:

1.1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 15 октябрендәге 4320 номерлы «2024 елда Казан шәһәрендә БРИКС илләре саммитын әзерләү һәм уздыру чорында транспорт чаралары хәрәкәтен, тукталышын һәм туктап торуын вакытлыча чикләү турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.1. 1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«1.2. БРИКС илләре саммитын әзерләү һәм уздыру чорында 2024 елның 22 октябрендә 00.00 сәгатьтән алып 23.59 сәгатькә кадәрге вакыт аралыгында Вишневский урамы буйлап, Подлужная, Николай Ершов, Шмидт, Лесгафт, Калинин, Тихомирнов, Петербург урамнары белән кисешкән урыннарда, Нурсолтан Назарбаев урамы буйлап, «Миллениум» күпереннән Габдулла Тукай урамына таба Островский, Спартак, Марсель Сәлимҗанов, Һади Такташ урамнары белән кисешкән урыннарда 4.1.1 «Туры хәрәкәт итү» юл билгеләрен урнаштыру өлешендә юл хәрәкәтен оештыруга вакытлыча үзгәрешләр кертергә»;

1.1.2. 1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«1.4. 2024 елның 22 октябрендә 00.00 сәгатьтән алып 2024 елның 24 октябрендә 23.59 сәгатькә кадәр вакыт аралыгында, Мехчылар урамы буенча

хәрәкәт иткәндә, Кызыл Татарстан урамына һәм, Габдулла Тукай урамы буенча хәрәкәт иткәндә, Татарстан урамына сул борылышларны вакытлыча рөхсәт итәргә»;

1.1.3. 1 номерлы кушымтадагы таблицага түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

| № т/б | Датасы һәм вакыты | Ябу урыны |
|---|---|---|
| «5 | 2024 елның 19 октябрендә 00.00 сәгатьтән алып 2024 елның 24 октябрендә 23.59 сәгатькә кадәр вакыт аралыгында | Оренбург Тракты урамы буенча 172 номерлы йорт янындагы автомобиль юлы буенча» |

1.1.4. 2 номерлы кушымтадагы таблицаның 1 пунктындагы «Ябу урыны» графасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- Агрономия урамы буенча, Нурсолтан Назарбаев урамыннан алып Ипподром урамына кадәр ике юнәлештә;

- Сеченов урамы буенча, Николай Ершов урамыннан алып 19кА номерлы йортка кадәр Сеченов урамы буенча»;

1.2. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

2. **Тәкъдим итәм:**

2.1. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә (Н.Д.Закиров) әлеге карар нигезендә Казан шәһәре урам-юл челтәренең югарыда күрсәтелгән участокларында юл хәрәкәте иминлеген саклауны контрольдә тотуны һәм оештыру-көйләү гамәлләрен башкаруны тәэмин итәргә;

2.2. Казан шәһәре Думасы аппаратының Мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) күрсәтелгән урам-юл челтәре участокларында транспорт чаралары хәрәкәтенә һәм аларны куеп торуга вакытлыча чикләү кертү турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка **йөклим**.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**